**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ГОРОДА ЛАИШЕВО**

ул. Коммунальная, д.3,
г.Лаишево,422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Коммунальная ур., 3 нче йорт,
Лаеш ш.,422610

тел: 8-(84378) -2-57-77, факс: 8-(84378) -2-50-62, e-mail:Gorod.La@tatar.ru

**2026 елның 24 марты** **8номер**

**КАРАР**

**16:24:170109:55 кадастр номерлы, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан җир участогы территориясенең межалау проектын раслау мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 39 нчы статьяларына, 2023 елның 18 декабрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне бүлешү турында»гы 131-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктуралар үсешен тәэмин итү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алу максатыннан, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең 2026 елның 24 мартындагы «Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир участогы территориясенең межалау проектын раслау мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында»гы 2567/исх номерлы мөрәҗәгате нигезендә:

1. 16:24:170109:55 кадастр номерлы, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан җир участогы территориясенең межалау проектын раслау мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә..

2. Ачык тыңлауларны үткәрү чорын – кызыксынучы затларга аларны үткәрү турында хәбәр ителгән мизгелдән алып ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә..

3. Эшче комиссиягә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир участогы территориясенең межалау проектын раслау мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү буенча әзерлек эшләрен башкарырга.

1.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр итүне әзерләргә;

1.2. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә басылып чыккан көннән башлап ике эш көне эчендә, карар кабул итү өчен документлар комплектын кушып, Татарстан Республикасында җирлекләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә мәгълүмат җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча) һәм Лаеш муниципаль районының рәсми

сайтында (Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://laishevo.tatarstan.ru/publichnoe-obsuzhdenie-5676969.htm веб-адресы буенча) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән башлап үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче В.А. Арефьев